Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Тимәш авыл җирлегенең
Тимәш авылы гражданнар җыены
**КАРАРЫ**

2022 елның 19 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Тимәш авыл җирлеге Тимәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1, 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаиләләре, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, ялгыз пенсионерлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юлэшчәнлеге: Молодежная урамына вак таш җәю, Школьная урамындагы юлларда чокырлар ремонтлау, Тимәш авылында юлларны кардан чистарту

« ӘЙЕ » « ЮК ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1842 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 1051.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 1051 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге составына керүче Тимәш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Тимәш авыл җирлеге Тимәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1, 2

төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаиләләре, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, ялгыз пенсионерлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме: Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: Молодежная урамына вак таш җәю, Школьная урамындагы юлларда чокырлар ремонтлау, Тимәш авылында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71Д (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 (мәдәният йорты), нефтьүткәргечләр урамы, 20 (Ромашкино РНУ утырышлар залы), Киров урамы, 1А («Ласточка» балалар бакчасы), Лесная урамы, 20, Лесная урамы,33 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль
берәмлеге башлыгы Р.М.Сираев